ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 422 от «20» 10 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 607 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының 2023 елның 16 октябрендәге 02-08-02-2023 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 430-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2018 елның 24 декабрендәге 607 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасының 2 нче пунктындагы 20 нче пунктчасында «файдалану белән бәйле эшләрне башкару» сүзләрен «файдалануны гамәлгә ашыру» сүзләренә алыштырырга;

1.2. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасының 2 пунктының 22 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"22) әлеге махсус икътисадый зонаның инженерлык, транспорт, социаль, инновация һәм башка инфраструктуралары объектларын төзү һәм (яисә) реконструкцияләү өчен теләсә кайсы типтагы махсус икътисадый зона чикләрендә яисә аңа якын территориядә урнашкан җир кишәрлеге, әлеге махсус икътисадый зонаның Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы яисә Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органы, яисә идарәче компания белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан "Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында" 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

0000012037

вәкаләтләр тапшырганда, идарәче компанияне махсус икътисадый зона белән идарә итүгә җәлеп итү турында карар кабул ителгән очракта;

1.3. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген аукцион формасында торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче О.Н.Павлов